**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ III ЧАКЫРЫЛЫШ XXIX СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 120**

Мөслим авылы «31» октябрь 2018 ел

**«Мөслим муниципаль районының контроль-хисап палатасы турында» 2010 елның 26 февралендәге I чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының XL сессиясе карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 29 декабрендәге 60 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнары эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2012 елның 17 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм муниципаль районның норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәгә» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Контроль-хисап палатасы Рәисе һәм инспекторлары муниципаль вазыйфаларны били.»

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Гарипов Р.Г. йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин